ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ БОЛГАЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2023 ел, 16 октябрь №105

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Олы Болгаер авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Олы Болгаер авыл җирлеге Советы номерлы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Олы Болгаер авыл җирлеге советының 2021 елның 15 июнҗ аендагы 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының « Олы Болгаер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)10 статьяның 5 пунктында «дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар җирләренә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2)10 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Шәһәр төзелеше регламентлары махсус икътисадый зоналар һәм алгарышлы үсеш территорияләре чикләрендә урнашкан урман фонды җирләре, җир өсте сулары, запас җирләре, махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләре, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр, җир кишәрлекләре өчен билгеләнми.».

3)20 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне башкарма комитет җитәкчесе карау өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) җирлекнең генераль планы кагыйдәләренең, муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасының мондый генераль планнарга яисә муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү нәтиҗәсендә барлыкка килгән туры килмәве;

1.1) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда үтәү өчен мәҗбүри керүе, җирдән файдалану һәм җирлектә төзелеш алып бару кагыйдәләрендә кертелгән, аэродром янындагы территорияләрдә урнашкан күчемсез милек объектларыннан файдалануның чикләүләрен бозуларны бетерү турында күрсәтмә,

2) территориаль зоналарның чикләрен үзгәртү, шәһәр төзелеше регламентларын үзгәртү турында тәкъдимнәр керү;

3) территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләренең урнашу урыны турында белешмәләрнең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында чагылдырылган, күрсәтелгән зоналар, территорияләр чикләренең урнашу урыны тасвирламасына туры килмәве;

3.1)Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына торак пунктларның чикләре турында белешмәләр керткәндә федераль закон нигезендә үзгәртелгән Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында булганәлеге торак пунктларның чикләренең урнашу урынын

тасвирлауга торак пунктларның(шул исәптән торак пунктларның чикләренең (торак пунктларның) җир кишәрлекләре чикләре кисешкән очракта)чикләре турында белешмәләренең туры килмәве;

4) шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән махсус шартлары булган зоналар, федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге истәлекле урыннар территорияләре чикләрендә тулысынча яки өлешчә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары белән файдалану чикләүләренең Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында булган әлеге зона территория чикләрендә күчемсез милекне куллану чикләүләренә туры килмәве;

5) территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны билгеләү, үзгәртү, туктату, мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен, федераль әһәмияттәге тарихи җирлек территориясен, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясен билгеләү, үзгәртү;

6) территорияне комплексłы үстерү турында карар кабул итү;

7) Кагыйдәләрдәге территориаль зоналарның чикләре турында белешмәләрБердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына территориаль зоналарның чикләре турында белешмәләр керткәндә федераль закон нигезендә үзгәртелгән Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрындагв әлеге территориаль зоналарның чикләре турында тасвирлауга туры килмәве.”.

2.Әлеге карарның 1 пунктның 1,2 пунктчалары 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә, әлеге карарның1 пунктның 3 пунктчасы 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Олы Болгаер авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Олы Болгаер авыл җирлегебашлыгы,
Олы Болгаер авыл җирлеге Советы рәисе З.И.Сәйфуллина